РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА
СТАРОЗЮРИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Школьная ул., д.1А, с. Старые Зюри,
422091
тел. (факс): (84360) 52-6-25,
E-mail: Szur.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

Мәктәп ур., 1 нче А йорт, Иске Җөри авылы,
422091
тел. (факс): (84360) 52-6-25,
E-mail: Szur.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318056 ОГРН 1021607154986 ИНН/КПП 1619000537/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 5**

**КАРАР**
**«15» апрель 2020 ел.**

Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге башлыгының «Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге территориясендә калдыклар җыюны һәм чыгаруны оештыру тәртибен раслау турында» 2009 елның 23 октябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" гы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 31 декабрендәге 503-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге башлыгының «Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге территориясендә калдыклар җыюны һәм чыгаруны оештыру тәртибен раслау турында» 2009 елның 23 октябрендәге 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге территориясендә калдыкларны җыю һәм чыгаруны оештыру Тәртибенә:

1) 2 бүлектә:

А) 2.6 пунктын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«2.6 калдыкларны җыю - аларны алга таба эшкәртүне, утильләштерүне, зарарсызландыруны башкару максатларында, аларны эшкәртүне, утильләштерүне, зарарсызландыруны, урнаштыруны гамәлгә ашыручы зат тарафыннан калдыкларны кабул итү.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Теләче муниципаль районы
Иске Җөри авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Мараков